ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 477-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 477-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 2 ноябре
№ 2209-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясының 8 өлешендәге 5 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 33 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш) аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5) «ВЕ» һәм «СЕ» категорияләре өчен 15 берәмлектән (суммар рәвештә).».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законының проекты «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (алга таба – 91-ТРЗ номерлы закон) федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнгән.

91-ТРЗ номерлы законның 10 статьясындагы 8 өлеше белән транспорт инфраструктурасы объектлары территориясендә транспорт чараларын кулланып гавами чаралар оештырганда һәм үткәргәндә оештырылган бер транспорт колоннасы составында транспорт чараларының максималь саны билгеләнгән.

Алар арасында «Е» категорияле транспорт чараларына карата 15 берәмлек күләмендә чикләүләр билгеләнгән.

Шул ук вакытта, бүгенге көндә «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрьдәге 196-ФЗ номерлы Федераль закон транспорт чаралары категорияләре арасында «Е» категориясен (транспорт чаралары составы) күздә тотмый, шул ук вакытта «ВЕ», «СЕ», «DE» яңа категорияләре кертелгән. Моңа бәйле рәвештә, 91-ТРЗ номерлы законның 10 статьясының 8 өлешендәге 5 пункты тиешле үзгәрешләр кертүне таләп итә.

Закон проекты белән «ВЕ» һәм «СЕ» категорияләре өчен бер оештырылган транспорт колоннасы составында транспорт чараларының максималь санын суммар 15 берәмлек дип билгеләү тәкъдим ителә.

«ВЕ» категориясе – прицеп белән тоташтырылган, рөхсәт ителгән максималь авырлыгы 750 килограммнан артык булган һәм йөксез автомобиль массасыннан артык булган «В» категорияле автомобильләр; прицеп белән тоташтырылган, рөхсәт ителгән максималь авырлыгы 750 килограммнан артык булган «В» категорияле автомобильләр, әгәр транспорт чараларының мондый составының рөхсәт ителгән максималь массасы 3 500 килограммнан артып китсә.

«СЕ» категориясе – прицеп белән тоташтырылган, рөхсәт ителгән максималь авырлыгы 750 килограммнан артык булган «С» категорияле автомобильләр.

Вәкаләтле органнар позициясен исәпкә алып, транспорт инфраструктурасы объектлары территориясендә гавами чаралар үткәргәндә башка яңа категорияле транспорт чараларын куллану каралмый.

Транспорт чараларының төркемчәләре 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясының 1 өлеше нигезендә турыдан-туры тиешле категорияләргә керә, шуңа күрә алар өчен күрсәткечләр билгеләү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.